БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 07 2024 ел № 192

Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 24 маендагы «Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 413 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 361 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Балтач муниципаль районының муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (1 кушымта).
2. Күрсәтелгән карар белән расланган Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (2 кушымта).
3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы «Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»151 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификацияле эшләр башкару шарты белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчү вакытына гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый, дип билгеләргә.
5. Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре оешмалары җитәкчеләренә хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп:

Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә, әлеге карар белән билгеләнгән хезмәткә түләү системасы кертүгә кадәр ике ай алдан, хезмәтнең җитди шартлары үзгәрү турында хәбәр итәргә.

6. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов